# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Александровка авыл җирлегенең Татар Карамалысы авылы торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**18 ноябрь 2023 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 18 ноябрендә 14.00 сәгатьтә үткәрелгән гражданнар җыенының «2024 елда 500 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Александровка авыл җирлеге Татар Карамалысы авылы территориясендә теркәлгән инвалидлардан; 80 яшьтән өлкәнрәк булган затлардан; көндезге бүлектә укучы студентлардан, ашыгыч хәрби хезмәт, контракт буенча хәрби хезмәт, мобилизация буенча хәрби хезмәт узучылардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме:

1) Татар Карамалысы авылы урамнарында яктырту челтәрләрен ремонтлау, урамнарны яктырту җайланмасы (лампаларны, энергияне сак тотучы яктырткычларны, электр товарларын сатып алу һәм урнаштыру, урам яктырткычларын агымдагы ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);

2) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Татар Карамалы бистәсендә Совет урамында янгын сүндерү гидрантын сатып алу һәм урнаштыру);

3) Татар Карамалысы авылы зиратын киртәләү өчен төзелеш материаллары сатып алу;

4) Татар Карамалысы авылында гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын тоту (аларга якын территорияләрдәге үләннәр чабышлары, ЯММ, запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

5) җирле әһәмияттәге юлларны кышкы чорда кардан чистарту (ГСМ сатып алу, трактор өчен запас частьләр сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

6) Татар Карамалысы авылында халыкның күпләп ял итү урыннарын (Сабантуй территориясе) ремонтлау (павильон урнаштыру, эскәмияләр урнаштыру, төзелеш материаллары сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;

7) су башняларын, скважиналарны су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын ремонтлау (су саклау зонасын төзекләндерү, төзелеш материаллары сатып алу, коймалар урнаштыру, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;

8) Татар Карамалысында Өлкәннәр көнен үткәрү өчен бүләкләр сатып алу.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 242 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 168 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен 168 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Александровка авыл җирлегенең Татар Карамалысы авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2024 елда 500 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Татар Карамалысы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, инвалидлардан, яшәүче олкәннәр (80 яшькә җиткән), көндезге формада белем алучы студентлардан, ашыгыч хәрби хезмәт, контракт буенча хәрби хезмәт, мобилизация буенча хәрби хезмәт узучылардан тыш, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме » дигән сорау буенча карар кабул итәргә:

1) Татар Карамалысы авылы урамнарында яктырту челтәрләрен ремонтлау, урамнарны яктырту җайланмасы (лампаларны, энергияне сак тотучы яктырткычларны, электр товарларын сатып алу һәм урнаштыру, урам яктырткычларын агымдагы ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);

2) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Татар Карамалысы авылы Совет урамында янгын сүндерү гидрантын сатып алу һәм урнаштыру);

3) Татар Карамалысы авылы зиратын киртәләү өчен төзелеш материаллары сатып алу; 4) Татар Карамалы торак пунктларында гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын тоту (аларга якын территорияләрдәге үләннәр чабышлары, ЯММ, запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

5) җирле әһәмияттәге юлларны кышкы чорда кардан чистарту (ГСМ сатып алу, трактор өчен запас частьләр сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

6) Татар Карамалысы авылында халыкның күпләп ял итү урыннарын (Сабантуй территориясе) ремонтлау (павильон урнаштыру, эскәмияләр урнаштыру, төзелеш материаллары сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;

7) су башняларын, скважиналарны су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын ремонтлау (су саклау зонасын төзекләндерү, төзелеш материаллары сатып алу, коймалар урнаштыру, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;

8) Татар Карамалысында Өлкәннәр көнен үткәрү өчен бүләкләр сатып алу Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Александровка авыл җирлегенең Татар мәгълүмати стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Александровка авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Сарман муниципаль районы
Александровка авыл җирлеге башлыгы,
халык җыенында рәислек итүче И.Ф.Вафин